


ЧАЯН

ISSN 0134-384

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * ИЮНЬ * 2016 * КАЗАН

12

Эльвира ДЫШАЕВА



Илдар НӘФИЕВ



АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

● Корал төзәүче (наводчица) Савченконы Украинага тапшыру ФСБның соңгы вакытта иң уңышлы операциясе итеп танылган.

● Сәясәтчеләр бердәм фикердә: күптән түгел генә Киевта узган гей-парадны Украинаның Европага арт яктан керүе дип бәяләделәр.

● «Шырдый» агентлыгы сораштырулары россиялеләрнең төп дошманнары дип АКШ, Төркия, ИГИЛ һәм җәй айларында икешәр атна су бирмәүләрен ачыклаган.

● Мәгариф министрлыгында БДИчылар сектасы барлыгы беленгән.

● Олимпия уеннары программасына химиклар һәм юристлар ярышы кертелергә мөмкин.

● Фотосурәт буенча тану программасы барлыкка килгән. Сайтка кереп кызларның чынлыкта кем икәннәрен йөзеннән, буй-сыныннан һәм авырлыгыннан белеп була.

● Инглиз галимнәре ташбаканың автомобиль фарасын гомерендә бер генә мәртәбә күрүен ачыклаганнар.

● Илебезнең кино кризисы барыннан да бигрәк попкорн сатучыларында чагылды.

● Сырхауханәләрдә кулланылышка “миңа сорап кына чыгарга” дигән талоннар кертәләр.

● Бер пенсионер әби супермаркетта геннары модификацияләнгән кишер белән телгә килгән.

● Быел, мәктәп укучыларын БДИ бирер алдыннан тикшергәндә, яңа алымнар кулланганнар. Алар террор һәм наркотиклар әйләнеше белән көрәшкәндә уңай нәтиҗә биргән булган.

● Баллы ризык эшкәртүчеләрне бала-чаганы юанайтуга китергәне өчен хөкемгә тартканнар.

● Кешене алыштыра ала торган компьютер уйлап тапканнар. Үзе эшлисе эшне ул хәтта икенче компьютерга күчерә ала.

● Макдоналдс клиентларын сораштыру мондый нәтиҗәгә китергән: гуманитар белемле сатучыларның гамбургерлары технарьларныкыннан тәмлерәк.

● Телевизион мелодрамаларда кадр артында елау барлыкка килгән.

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Көнчелек бәхетле итми, киресенчә, ул кешенең бавырын черетә...

Алмаз Хәмзин: Бавырның дошманы – аракы, Рашат дус! Эх, шуны белә торып та, “көнчелек”не гаепле итәсең...

Р. Н.: Бер үлеп, яңадан туып карасаң иде ул!

А. Х.: Алай итеп була торган булса, синең белән миңа бер туу да мөмкин булмас иде.

Р. Н.: ГАИга йөз суыңны түккәнче йөз сумыңны “түгүең” хәерлерәк.


А. Х.: Ә хөкүмәтнең нәфесе ГАИга караганда мәкерлерәк.

Р. Н.: Яшьлек уза да китә, ә картлык?

А. Х.: Картлык – күпләргә тәтеми торган Зур Шатлык!

Р. Н.: Башлы хатынга баш булуы кыен.

А. Х.: Шуңа күрә аларның вазыйфасын үти муен!



Александр СЕРГЕЕВ



Михаил НИКИТИН

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

● Еш кына хайваннарны яклаучылар кешеләр белән этләшә.

● Бакчагызда демократия ясап карагыз — аны чүп басып китәчәк.

● Гомер кыска дип зарланабыз, ә үзебез вакытны кая куярга белмибез.

● Яшьлек үтә — монысы әле ярый. Ә менә картлык үтү — инде чын бәла.

● Тәртип урнаштырырга теләгәннәрдән соң, дөньяда бик күп тәртипсезлек кала.

● Безнең халык кына ялда эшли, ә эштә ял итә ала.

● Әгәр дә берәр нинди ахмаклык даими рәвештә кабатланып торса, ул законга әверелә.

ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Европада уздырылган Евро-2016 инде футбол чемпионатлары тарихына керергә өлгерде. Ләкин кабатланмас матчлар, яңа уен техникасы һәм футбол йолдызлары белән генә түгел. Беренче чиратта ул җанатарларның котырынуы белән истә калыр. Аларның коточкыч кыланышлары сурәтләнгән кадрлар бөтен сайтларны һәм телевизион программаларны әйләнеп чыкты. Моның белән бәйле фикер туа: бәлки җанатарлар арасында рәсмиләштерелгән сугышлар уздырыргадыр? Шәһәр читендә берәр нинди буш мәйдан бирергә дә — шунда туйганчы дөмбәсләшсеннәр...


Т. ХӘЙДӘРОВ

минзәлә

– Бу очракта яңа проблема туачак: аларның үз җанатарлары барлыкка киләчәк бит... – диде Шомбай ага, укучының тәкъдиме белән танышкач.







Банкларның халыкка кредит камыты кидерү нәтиҗәсендә ил коллекторның канализация торбасы гына түгел икәнлеген белде. Ул халыкның банк бурычларын кайтара алмый торган өлешен калтыратып тотучы кырыс профессия иясе дә икән. Бу хезмәтнең барлыкка килүенә бик кыска вакыт үтүгә карамастан, "бурыч кайтаручылар" яманат яуларга өлгерделәр инде. Көн саен диярлек аларның яңа "батырлыклары" турында хәбәр килә: йә бичара хатынны көчләгәннәр, йә балалар бакчасын шартлатабыз дип яныйлар, йә матди яктан кысынкы хәлдә калган бурычлының йортына ут төртәләр...

Бу куркыныч шаукым Татарстанны да читләтеп узмады. Узган ел, мәсәлән, Чистайда ике коллектор... участковыйдан 100 мең сум кысканнар. Бу юлы банк бурычлары өчен түгел, ә юл-транспорт вакыйгасы турында ялган белешмә өчен. Үзләренең сүзенә караганда, бу эштән буш вакытта "шабашка" гына булган. Чаллыда, тиешле бурычын тизрәк кайтартыр өчен, пенсионер хатынның подъезд стеналарын һәм фатир ишеген кара буяу белән пычратып чыкканнар. Шул ук шәһәрдә бер хатынның фоторәсеменә "Сак булыгыз, СПИД!" дигән язу куеп, шәһәр буенча таратканнар. Түбән Камада яшәүче бурычлыга дә психик атака кичерергә туры килгән. Шәһәрдә аның... гей булуы турында листовкалар барлыкка килгән. Бу да ярдәм итмәгәч, аның 80 яшьлек анасын көчләү белән янаганнар...

Коллекторларның халыкны даими рәвештә дер селкетеп куркытып торуларына карамастан, республикада аларга карата бары тик ике җинаять эше кузгатылган. Кешеләр бер уттан икенче утка эләгүдән курка микәнни?

Быел Татарстан Республикасының Җәмгыять палатасы янында коллекторларның законсыз гамәлләреннән саклау үзәге ачылды. Андагы юристлар һәр рәнҗетелгән һәм кимсетелгән кешегә ярдәмгә килергә әзер. Закон чыгару әһелләре дә бу проблемадан читтә калмады. Дәүләт советында коммунистлар бу яртылаш җинаятьчел оешманы, гомумән, ябарга дигән тәкъдим белән чыктылар. Ләкин тәкъдим узмады — имеш, бу мәсьәлә федераль хакимият карамагында, һәм шуңа күрә проблеманы Мәскәү хәл итәргә тиеш. Думада исә закон проектын кабул итү һаман кичектерелеп килә — күп төзәтмәләр кертергә кирәк...

Депутатлар баш кашыган арада, коллектор агентлыкларының Милли ассоциациясе талпынып куйды. Ул ашыгыч рәвештә чиктән ашкан "профессионаллар"ның аз булса да дәрәҗәсен күтәрү максаты белән алар өчен "этик кодекс" кабул итте. Тик кодекс закон көченә ия түгел, һәм аның җиңелчә бармак янау гына булып калмагае.

Шунысы кызыклы, шундый тискәре халәткә карамастан, быелның беренче кварталында гына Татарстанның эш бирүчеләре коллектор вакансияләрен, узган елга караганда, утыз процентка артыграк тәкъдим иттеләр. Профессиянең популярлыгы арта. Бүгенге көнгә ярты миллионнан артык россияленең банкларга 500 мең сумнан артык бурычы бар. Татарстанда андыйларның саны — 14 мең. Чалгычыга басу киң! Бурыч — эче бурыч, диләр бит. Ә мондый коллекторлар белән — аның иң зәһәре.

Людмила САФИУЛЛИНА

Валерий ТАРАСЕНКО



Валентин ДРУЖИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Алексей МАМАЕВ





• • •

Әдәбият укытучысы студенттан сорый:

— Әгәр дә сезгә исән яки үлгән кайсы да булса язучы белән очрашып сөйләшергә мөмкинчелек бар дисәләр, сез кемне сайлап алыр идегез?

— Исәнен!

• • •

Махсус максат белән хәерче рәвешендә чиркәү янына утыртылган оперуполномоченный К. икенче көнне үк, ике дә уйламыйча, эшеннән китәргә гариза бирде.

• • •

Бөтен гаишниклар: “Син эчтеңме?” — дип сорыйлар. Шуларның, ичмасам, берсе генә булса да: “Син ашадыңмы?” яки: “Эчкәч берәр нәрсә кабып куйдыңмы?” — дип кызыксынып караганы юк.

• • •

Социологик сораштыру. Гаиләгезнең иң яраткан бәйрәме нинди?

— Яңа Ел.

— 8 Март.

— Масленица.

— Ур-ра, ниһаять кайнар су бирделәр!

• • •

Әбисе оныгы белән, тычкан — хайван, лайклар — этләр, ә ссылка — Ленин Шушенскоеда икәнен исбатлый-исбатлый, талашып киткән.

• • •

— Сәлим! Син иншаңда ни дип яздың? “Якшәмбе көнне искиткеч шимбә иртәсе булды”. Ничек шулай була ала ул?

— Ничек сезгә аңлатыйм, Зәйнәп Хәйрулловна, Бөек Октябрь революциясен ноябрьдә үткәрәбез бит.

• • •

Украинаның хәзерге тарих дәреслеге:

— Теләсә нинди чын тарихи фактларның бер-берсенә туры килүен чын очраклылык дип санарга.

• • •

Әгәр дә бөтен илләр белән хатын-кызлар җитәкчелек итсә, дөньяда сугышлар булмас иде. Бары тик илләр күбәеп, алар бер-берсе белән сөйләшмәсләр генә иде.





БЕЛЕМНӘРНЕ — ТОРМЫШКА!

Казанда яшәүче физика-математика фәннәре кандидаты кандидат Юрий Горюновка теорияне төптән белүнең реаль тормышта кирәге чыккан. Тизлекне арттырган өчен "чәпелгән" штраф белән ризалашмыйча, ул "бәхет хаты"на беркетелгән фоторәсемнәрне җентекләп өйрәнгән. Физик радарның артык түбән урнашкан булуына игътибар иткән. Иренмичә, ул приборның бөтен документларын өйрәнгән һәм датчикны болай урнаштыруның тизлек күрсәткечләренең артуына китерүне ачыклаган. Фәнгә каршы барып булмый — суд дәгъвачы белән килешкән һәм штрафны гамәлдән чыгарган. Ләкин ЮХИДИнең чигенергә исәбе юк — ул суд карарына апелляция биргән.

СЫЙФАТСЫЗ "ИПИ ШҮРЛЕГЕ"

Чиләбе өлкәсендә яшәүче Виктория М.га теш казнасыннан колак кагарга туры килгән. Бәхетенә каршы, ясалмасыннан. Бу ханым дөрес куелмаган теш протезы өчен стоматология клиникасыннан суд аша 80 мең сум алган булган. Ачулары чыккан стоматологлар эшләнмәне кире кайтаруны таләп иткәннәр. Ләкин пациентка бу клиника белгечләре алдында тагын авызын ачудан катгый рәвештә баш тарткан. Озакка сузылган сөйләшүләрдән соң, алар уртак фикергә килгән: клиника тиешле сумманың бер өлешен түләгән, ә клиент ханым протезны башка клиникада алдырып, аны брак ясаучыларга кайтарып биргән. Шуннан соң гына теш ясау осталары калган акчаны түләгән. Сыйфатсыз протезны исә эретергә җибәргәннәр.

ГӨНАҺ КЫЛМА!

Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Югары дини идарәсе чит кешенең Wi-Fi җайланмасын файдалануны караклыкка тиңләп, моны гөнаһ дип тану турында фәтва чыгарган. Ул гына түгел, чит челтәрдән файдалану Интернетның тизлеген киметүе һәм законлы хуҗасына мораль зыян китерүе мөмкин. Ә менә һәркемгә ачык Wi-Fi дан файдалану һич тә гөнаһ түгел. Гарәп илләрендә әлегә кадәр каракларның кулларын кисүне истә тотсак, яңа карар һичсүзсез үтәләчәк.



Дмитрий КОНОНОВ



Виталий ДУБИНИН



Чуар тавык

(өлкәннәр өчен әкият)

Булган, ди, әби белән бабайның чуар тавыгы. Шундый арык һәм мескен йолкыш. Хуҗалыкта аннан бернинди файда булмаган. Суеп пешерсәң дә бер тамчы өйрәсе чыгарлык түгел. Шулай беркөнне шул тавык кетмәгәндә алтын күкәй салган, ди. Бабай күкәйгә карап торган да, "Шаяртадыр бу йолкыш!" — дип уйлап куйган. Шулай да күкәйне тешләп караган, чак кына тешсез калмаган — ул чынлап та затлы булып чыккан. Бабай аны ватарга тырышып караган: өстәлгә дә, идәнгә дә, мичкә дә бәреп караган... Ватылмый гына икән. Шуннан соң чыккан, ди, картлач ишегалдына, күкәйне карчыгына күрсәтергә. Анда әби тәпке белән бәрәңге өя икән.

– Карале, карчык, миндә нәрсә бар! Ватарга иде аны берәр ничек!

Әби күкәйне тәпке белән бәргәләп караган. Барыбер ватылмый, ди. Шул вакыт алар яныннан тычкан чабып бара икән. Ул әби белән бабай янына килгән һәм:

– Нишлисез, картлачлар? — дип сораган.


Күкәй ватабыз, — дигән мышнап чыккан әби. Тычкан игътибар белән күкәйгә караган да:

Сез нәрсә, акылдан яздыгызмы әллә? — дигән. — Ул алтын ич. Сез аны беркайчан да вата алмаячаксыз!

Тычкан шулай дигән дә, әби белән бабайга сүз әйтергә дә бирмичә, җитез генә затлы күкәйне каядыр тәгәрәтеп алып киткән. Алар аны бүтән беркайчан да күрмәгәннәр. Дөрес, соңыннан алтын әйберләр белән сату итүче кибеттә кемдер алтын күкәй күргән, дип сөйләгәннәр. Менә шундый әкият.



Александр ЛЕВИТИН



Андрей КЛИМОВ



Игорь КИЙКО



Александр КОСМЫЛИН





Ринат МИРЗАЯНОВ

Илдар КӘБИРОВ

СӘРИЯНЕҢ “АЛТЫНЫ”

Беренче мәртәбә мин аны дусларымның бакчасында күрдем. Тәүге тәэсирне, мәгълүм булганча, иң дөресе дип әйтәләр, чыннан да ул миңа бик ошады. Шуннан соң мин тагын бераз эчтем һәм ул сокландыргычка әйләнде, ә өченче коньяктан соң – искиткеч булып күренде. Ул кичәдә мине күрсәгез иде! Мин күкләргә күтәрелдем! Билгеле, мин аңа өйләнергә вәгъдә бирмәдем, ләкин уй-фикерләрем булмады дип әйтә алмыйм. Мин аңа Фирдүс җырларын җырладым, Кадыйрова әсәрләреннән өзекләр сиптем һәм КВНның соңгы чыгышындагы кайбер кызыкларны, персонажларны уйнап көлдердем. Кунакчыл хуҗалар бездән туеп йокларга яткач, мин аңа күл кырыенда йөреп килергә тәкъдим иттем. Төн, күктә йолдызлар, юлыбыз кырлар аша боргаланып бара, еракта серле кара су өсте… Зеңгелдәгән тынычлык хөкем сөрә иде ул төнне! Бары тик аның яңгыравыклы тавышы гына ишетелә. Ул үзенең яраткан “Җомга”сын җырлый, ә кайдадыр якындагы авылда әшәке сүзле такмаклар акыралар, әлеге такмак безгә ода кебек яңгырый һәм безне күкләргә чөя сыман… Аннан соң без шул җылы кара сулы күлдә коендык, әйтерсең лә бу рәхәтлек мәңгелеккә сузылыр төсле иде.

Ярга чыккач, мин аның аяк астына барлык йолдызларны түшәргә һәм бар җиһанны ташларга сүз бирдем. Мин вәгъдәләрне бирергә беркайчан да саранланмыйм, шулай тәрбияләнгәнмен.

Озакламый без бакчага әйләнеп кайттык. Ул йокларга икенче этажга менеп китте, ә мин… Җә, ярый, бу турыда, монысы безнең арада калсын.

Мин аннан иртәрәк тордым. Кояш, ничектер, икенче төрлерәк елмая төсле! Сәгать җиделәрдә ул безнең янга чыкты. Ниһаять без таныштык. Аның исеме Сәрия икән.

Тиздән ул өенә кайтырга җыена башлады. Станциядә мин аны кочакладым. “Ә син хәтерлисеңме кичә миңа нәрсә вәгъдә иттең?“ “Билгеле, хәтерлим, – дидем мин, – бөтен дөньяны бүләк итәргә“. Һәм аңа электричкага билет алып бирдем.

Шуннан соң без тагын ике мәртәбә очраштык. Мин аның аяк астына барлык булган акчамны чәчтем. Мең тәңкә акча түгелмени, дуслары ни генә дисәләр дә…

Инде без аның белән өч ел бергә яшибез. Ул Шиһаповның да кем икәнен белми икән, Фирдүсне дә яратмый, Кадыйрованы да укымый, Җомга турындагы җырны ишеткәне дә юк һәм КВНны, гомумән, карамый. Шуңа өстәп, төнлә коенуларны яратмый икән. Аның күңелен нәрсә белән яулаганмындыр? Әлеге зәңгәр күзле бәхет кисәге миңа ничек насыйп булган?

Бу турыда савыт-саба, керләр юганда, үтүкләгәндә, кибеттән ашамлыклар ташыганда күп уйлыйм. Мондый уйлар ашарга пешергәндә, идән юганда, аяк киемнәрен чистартканда, иртән караватына кофе китергәндә, бәдрәф тазартканда һәм гөлләргә су сипкәндә бик еш башыма килә. Кайчагында мин аны түгел, ә ул мине яулап алмады микән дип уйлыйм. ЗАГСтагы ханым, җәза биргәндәге сыман, назлы елмайгандай булып ерткыч тешләрен күрсәткән иде… Юкка түгелдер, күрәсең.



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Заһир ХӘКИМОВ

– Беләсе иде, аларны допингка тикшергәннәр микән?

Таһир МУМУЕВ

ЙӨРӘК СЕРЕ

Әй авыр ла яшәү дөньяларда –
Ник газаплый мине бу язмыш?
Җүләр-тилеләрне җенем сөйми,
Акыллылар белән мин – ялгыз…



ТУП ТИРӘЛИ

Виталий ПОДВИЦКИЙ





Эрнест ДЫШАЕВ









Нажия БӘХТИЕВА

Анонимка

Сезгә кешеләрнең бөтенләй намусларын югалтулары һәм дәүләт тарафыннан күрсәтелгән игътибар һәм кайгыртуның кадерен белмәүләре турында хәбәр итәргә телим.

Элек табибка эләгү өчен регистратураны сугышып алырга кирәк иде. Ә хәзер — рәхим ит, интернет аша языласың да поликлиникадан шалтыратканнарын көтәсең. Анализлар тапшыру өчен чиратны да шулай ук көтәсең.

Кайберәүләрнең чираты җитә дә бит! Дарулар кыйммәт. Аның каравы, алдан ук кисәтеп куялар — аларның яртысы ялган дару. Кисәтмәсәләр дә ярый иде. Мәгълүмат чараларына да сәламәт халык өчен көрәш эшен йөкләделәр. Радиодан төгәл вакыт сигналлары да кыска яңалыклар, ә төп вакыт — сәламәтлекне саклау һәм ныгыту өчен аппаратлар һәм дарулар. Сериалның ни турында булганлыгын хәтерләмим, ә кавык, хатын-кызлар өчен шәхси әйберләрен, сару кайнаудан даруларны үлгәнгә кадәр онытасым юк. Менә бу кеше турында кайгырту, ичмасам!


Сәүдәне генә алыйк. Кеше турында кайгыртмасалар, барлык каналлар буенча ГМО, пальма мае, нитратлар, срогы чыккан товарлар турында сөйләрләр идемени? Йә ялган товарны чын товардан ничек аерырга икәнен аңлатырлар идемени? Ә кабахәт репортёрларга йоклап утырган депутатны фотога төшереп, аның миллионнары турында язарга гына булсын. Ә халык саныннан да күбрәк закон язулары турында — ләм-мим! Алар бит корыч коючыларга, комбайнерларга балда-майда йөзеп яшәгәннәре өчен оят булсын дип, пенсиягә дә соңрак чыгарга булдылар.

Чиновникның да тормышы җиңеллләрдән түгел. Буталып, бер-ике миллиардны ялгыш кесәңә салдың — бернинди рәхим-шәфкать көтмә. Йә берничә ай өеңнән чыгармыйча тоталар, йә яңа кәнәфигә ияләнергә мәҗбүр итәләр.

Әшәке бездә халык, яхшылыкның кадерен белми. Аңа базын бәрәңге белән тутырырга да Интернетта рәсемнәр карап утырырга булсын. Пенсия фондына үч итеп, икътисадны бөтенләй какшатыр өчен яңа мәкер уйлап тапкан. Машиналарын ташлап, велосипедта йөри башлаган. Ә дәүләткә килгән зыянның очына чыгарлык түгел: салымнар, техосмотр, бензин, штрафлар… Казнага акчаны кемнән җыярга? Өстәвенә, сер итеп кенә әйтим, аноним пенсионерлар җәмгыяте барлыкка килде. Алар бит, медицинаның тырышлыгына карамастан, озак яшиләр, сабакылар. Бөтен җирдә төпченеп йөриләр. Йә тарифлар белән риза түгел, йә капремонт өчен түләргә теләмиләр. Тыныч кына утырасы бит — юк, йә иртән урамда йөгерәләр, йә өйләрендә компьютерда эшләргә өйрәнәләр. Үзләренең 10 меңлек пенсияләренә башка сыймаслык 4 процент компенсация алган килеш, яшерен рәвештә урам себерүче, вахтёр, бала караучы булып эшлиләр һәм илебезнең икътисадына төзәлмәс зарар китерәләр.

Сер итеп сезгә халык арасында хөкем сөргән менә шундый начар күренешләр турында язарга булдым.

Виктор ФЁДОРОВ



Эрнест ДЫШАЕВ



Сергей ЕРМИЛОВ



Александр АЛЁШИН



Евгений ОБУХОВ

АВЫЛ БУЙЛАП

Ул иртүк торып авылның берләнбер зур урамына чыкты да “Иртә буран, кич тә буран” җырын акырып җырларга тотынды. Карлыккан тавышына тончыгып, бераз туктап торды — куркыныч хәлгә килгән юан талның ботак очларындагы каргалар аңа аптырап карап торалар иде. Ул караңгы чырае белән урам буйлап тезелгән йортларга күз төшереп алды да, тагын бер мәртәбә җырын мыгырдап куйды һәм, чокыр-чакырга абына-сөртенә, бөтен дөньяны сүгә-каргый юлын дәвам итте. Авыл аның фикере белән килеште, күрәсең, эндәшмәде. Ул тагын дөньяның “әнкәсен” искә төшерде. Авыл ник каршы сүз әйтсен?..

Туктап торганан соң, ул, кайчан булса да кирәге чыгуы бар, дип, кесәсендәге шешәсеннән чирек өлеш калган аракысын авызына готкылдатты. Шуннан соң балакларына бутала-абына чут егылмый, чалбарын салды. Аны муенына урады һәм, койманың бер тактасын кубарып, шәп-шәрә артын боргалап тәрәзә янынннан үтте. Аннары шул тирәдән таяк табып, тәрәзә шакыды һәм, исерә төшеп, нигәдер диваналанып куйды. Эчтән берәү дә җавап бирмәде, тәрәзәсен дә ачмады һәм “еракка” да җибәрмәде. Хәер, кем җибәрсен, ул бит авылда соңгы көннәренә хәтле берүзе яшәргә калган кеше, ә якындагы авылга утыз алты чакрымлап. Монда айга ике тапкыр автолавка килгәли дә, аннан әллә ничә елга бер — сайлау комитетыннан урна белән берәү...

Ул, нигәдер, русча “дорогая моя столица” дигән җырны улап җырларга тотынды... һәм күңелендә рәхәтлек тойды.

Ринат МӘННАН

ПАЛЬМА МАЕ


Байлар китә ял итәргә
Пальма үскән илләргә...
Пальма маеннан куркалар —
Вакытыннан алда алар
Теләмиләр үләргә.

Моны һәр бай яхшы белә —
Нигә аны кабарга.
Пальма мае ашап нигә
Алда пальма илләреннән
Мәңге колак кагарга!

КУРЫКМЫЙЛАР

Хәмер сату — адым саен,
Һәр урамда берничә...
Айныткычлар бетерелде,
Халык курыкмый эчә!





Илдус АЗИМОВ



КАДЕРСЕЗ ҮСЕНТЕЛӘР

Кадерле Чаян! Парклар һәм скверлар елы шәһәребезнең яшел почмакларын тәртипкә китерде. Ә менә Ленин дамбасын яшелләндерү генә килеп чыкмады. Яшел агачлар утырту 2013 елдан башланган иде инде. Кызганыч, утырткан тирәкләр эссегә чыдый алмыйча үсеп китә алмады, кайберләре исә салкыннарда туңып һәлак булды. Үткән ел талымлы тирәкләргә кул селтәп, 300 ләп шомырт утырттылар. Һәр үсентене су белән тәэмин итеп коймa белән дә чикләделәр дә оныттылар. Башка су да сибелмәде, кышка да җылытып томаланмады.

Шунысы кызык, "корыган" агачлардан ерак та түгел яңа төзелгән гадел хөкем Сарае янында үскән затлы түтәлләрне су сибү машинасы көне-төне коендыра. Нишләп шундый үсентеләр генә кадерле икән безнең җитәкчеләргә?

Н. КӘЛИМУЛЛИНА

КАЗАН

КАЙСЫСЫ ӘҺӘМИЯТЛЕРӘК?

Хөрмәтле редакция! Узган ел, Шәйхетдинов микрорайонында урнашкан балалар поликлиникасы, зур төзекләндерү эшләреннән соң эшли башлады. Яңа буялган диварлар, кабинетлардагы яңа ишекләр, идәндәге матур плитәләр — күзләрне сөендереп нур чәчеп тора. Күп тә үтмәде, ишектә: "Аяк киеменнән керү катгый тыела!" дигән язу барлыкка килде. Бушка бирелә торган бахилалар булмаганлыктан чарасын да тиз таптылар. Олысы-кечесе, хәтта авыру балалар да аяк киемен салырга мәҗбүр. Салмыйсың икән — кермисең! Менә шундый кагыйдәләр хәзер бездә. Ярый ла, ишеткән-белгәннәр үзләре белән икенче аяк киеме алып килә. Ә белмәгәннәр салкын плитә идәндә бер кат оекбаштан тәпили. Дәвалаучы табибларга чират аз булмаганлыктан, утыргычлар да бар кешегә җитәрлек түгел. Бер авыруны дәваларга килеп, икенчесен эләктерүеңне көт тә тор. Бары бер нәрсә аңлашылмый: әлеге алым балаларның исәнлеген кайгыртумы, әллә инде плитә идәннәрнең чисталыгын саклаумы?

Азнакай хастаханәсенә килүчеләр.

АЗНАКАЙ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Тормыштан зарланма — аның да булмавы мөмкин иде бит.

Хатын-кызлар һәм филләр беркайчан да рәнҗетүне онытмыйлар.

Тормыш сез уйлаганча гади түгел. Ул күпкә гадирәк.

Безнең гомер үзебездән башка уза: без һәрвакыт үткәннәр белән өмет арасында.

Тормыш ашыгып язган хат шикелле: бик кыска һәм хаталар белән тулы.

Ирләр киләләр һәм китәләр. Ә кайберләре кала да әле.

Олыгайган саен, тән һава үзгәрешләренә сизгеррәк була бара, ә һава хәле һаман ешрак һәм ешрак үзгәрә башлый.

Тормышта бөтен нәрсә дә өмет булып башлана һәм гадәт булып тәмамлана.

Гомер буе абынып яшәүгә караганда, бер тапкыр егылу хәерлерәк.

Тормыш сабаклары араларындагы тәнәфесләр белән гүзәл.

Әгәр дә син тугансың икән, тормыштан зарланырга соң инде.

Дусларың һәм дошманнарың бар икән, бик яхшы: дуслар ярдәм итәр, дошманнар — өйрәтер.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)

Виктор ФЁДОРОВ



ЧАЯН шифаханәсе



КӨЛКЕ ТЕРАПИЯСЕ

Авыру теге дөньяга китмәсен өчен табибның аның янынннан китүе яхшырак.

Һәр авыру да безнең кесә өчен түгел.

Билгеле булганча, выкыт – үзе дәва. Шуңа күрә аны табибларга әрәм итмәгез.

Бездә табиблар кулына эләккәнче үзеңә терелеп өлгерергә кирәк.

Түләүсез медицинадан да кыйммәт нәрсә юк.

Үз авырулары белән көрәшергә хәле калмагач, табиб пенсиягә китә.

Медицинаның мөмкинлекләре чиксез. Пациентның мөмкинлекләре чикләнгән.



Михаил ЛАРИЧЕВ

Рөстәм ЗАРИПОВ

ХИРУРГ МОНОЛОГЫ

Кемнең генә корсагын ярсам да,
Гел бер нәрсәгә мин юлыктым;
Кеше карбыз түгел: шуны күреп,
Кырыс хакыйкатьтән курыкмыйм.



Илдус АЗИМОВ



Александр СЕРГЕЕВ

БАР ИДЕ ШУНДЫЙ ЧАКЛАР...

Мин, педагогика институтының музыка факультетын тәмамлап филармониягә эшкә килгәндә әле Илһам Шакиров белән Әлфия Афзаловадан башка берәүгә дә микрофонга җырлау тәтеми иде. Дөресрәге, филармониянең теләсә кемгә аппаратура җыештырып, гастрольләргә чыгарып җибәрергә нияте дә юк иде дип әйтимме?.. Безнең эшләр, хәлләр шундыйрак чорга туры килде. Шулай да, тора-бара, оештырылган концерт бригада җырчыларының ниндидер юллар белән тавыш көчәйткеч аппаратурасы юнәтеп, һәрберсе каяндыр микрофон табып, сәхнәгә чыкканда үзенекен микшер пультына тоташтырып, борынны томалагач чыккан тавыш белән җырлап керәләр дә, микшердан микрофонын өзеп, сумкаларына тыгалар иде. Шулай йөрибез. Минем беренче мәртәбә профессионал сәхнәгә басуым шундый очракка тап булды. Җитмәсә, беренче концертыбыз безнең авылдан башланды. Нишлисең, күрделәр инде авылдашларым минем хәерчелекне. Ләкин бу хәл миңа көтелмәгән уңыш китерде. Нәфисә Василовалар, Рәбига Сибгатуллиналар, Хәнәви Шәйдуллиннар чыгалар да микрофоннарыннан шытыр-пытыр, үз тавышларына охшамаган сәер аваз белән җырлап кереп китәләр, шуңа кул чабулар сыек килеп чыга икән. Ә мин, каушап кына чыгам да, нинди тавышым бар, шул мөмкинлектә җырлыйм. Һәр җыр саен — бис. Артист дусларым миңа кырын карап йөри башладылар. Биска җырлавым һәр авылда, һәр шәһәрдә дәвам итте. Ахыр чиктә, Хәнәви яныма килде дә:

— Мә, минем микрофонга җырла, безнеке кебек тавышың бозылып чыксын. А ту син безнең мачтырлыкны бетерәсең, — диде.

Рәхмәт, Хәнәвигә. Инде микрофонсыз җырлап тавышым утыра, карлыга башлаган иде.


Еллар үткән саен, Хәнәвинең шул игелеге еш искә төшә. Ярдәмчел егет, шәп җырчы иде мәрхүм. Урыны җәннәттә булсын!

Филармониядә миңа озак эшләргә туры килмәде. Киткән чакта дустыма үземнең репертуарымда булган яхшы җырларымны бүләк итеп калдырдым. “Бөрьян егетләре”, “Яле, яле”, “Гөлнәзирә” шуларның иң популярлары иде. Ул шушы җырлары һәм “Тары җире, киндер җире” белән халыкка танылды.

Алмаз ХӘМЗИН



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 12, 1966


Айдар УТӘГӘНЕВ, «Чаян» № 15, 1978

Александр АЛЁШИН



АЛЛЕРГИЯ

Рашат Низами:
Үлән яки чәчәк тузанымы?
Болар миңа пүчтәк бер нәрсә.

Алмаз ХӘМЗИН:
Әтәчләнеп йөргән идең, әнә,
Сәлимәнең бүксәсе үсә!

ХЫЯЛ

Рашат Низами:
Кабартылган шардай күтәрәбез
Дәүләтчелек дигән хыялны.

Алмаз Хәмзин:
Алгы максат – андый изге хыял,
Ә хәзергә бергәлектә яшик
Һәм узара булмыйк зыянлы.

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

● Ат кебек эшләсәгез, солыга җитәчәк...

● Түрә ялга китә икән, аның кул астында эшләүчеләргә дә өстәмә ял булачак...

● Әгәр түрәгез сезнең белән ягымлы сөйләшә башласа, тиздән икегезнең берсен эштән куачаклар...

● Кешене ике нәрсә эшләргә мәҗбүр итә: хезмәт хакы алу һәм аны югалту мөмкинлеге...

● Сынамыш: эшкә йөрү — акчага...

● Түрә турында йә яхшы сүз сөйлә, йә яңа эш урыны эзлә...

● Авыр эшкә урнашу җиңелрәк...

● Тирән йокы гомерне озайтып кына калмый, эш сәгатен дә кыскарта...

Нияз БИШБАЛТА тупламасыннан.

Дамир ФАЗЫЛҖАНОВ

Беренче караштан

— Туташ, сезнең күзләрегез йолдыз кебек, карашыгыз диңгез кебек тирән...

— Ә сезнең, егет, хезмәт хакыгыз күпме инде?

— Илле мең... Сезнең йөрешегез нәзакәтле һәм буегыз шундый зифа...

— Ә машинаң501 бармы?

— Бар... Мерседес... Ә йөзегез иртәнге сафлык кебек...

— Ә фатирың бармы соң?

— Ике бүлмәле. Берүзем яшим... Менә сезнең йортыгыз да...

— Фатирга хәтле озатып куй инде... Синең әти-әниең дә гади кеше түгелдер инде?

— Әти депутат. Әни — эшмәкәр. Менә сезнең фатирыгыз да...


— Мин сине бертуктаусыз тыңларга әзер...

— Ярый, мин киттем...

— Әй, син кая? Әйдә, кер, һәм бүтән беркая да чыкмыйсың... Беренче караштан гашыйк булдым бит мин сиңа! Күзләрең йолдыз кебек янып тора. Йөрешең шундый нәзакәтле... Алдамаган гына булсаң иде...

Александр КОСМЫЛИН





Алексей БУЛАТОВ



ЧуАр пресса

ХАТ

Безнең хат ташучылар бөтен дөньяда иң тапкырлар. Бервакыт Мәскәүдә яшәүче Павел Балешенкога почта белән винил пластинка килгән. Проблемасы шунда: ул почта ящигына сыймаган. Хат ташучы, озак уйлап тормыйча, пластинканы урталай сындырган һәм конвертны бөкләп, почта тартмасына салган.

МАЙМЫЛЧА

Кениядә маймыл "Гтару" ГЭСының түбәсенә менгән һәм тотынып кала алмыйча трансформаторга төшкән. Бу утның сүнүенә китергән. Нәтиҗәдә, төп энергия белән тәэмин итүче аппаратның сүнүе илне караңгылыкка чумдырган. Шунысы гаҗәпләндерә маймыл исән калган һәм хәтта бөтен Кениягә даны таралган.

АМЕРИКАНЧА АРИФМЕТИКА

Американың Алабама штатындагы математика укытучысы, тормыштан артта калмаска исәп итеп, актуаль темага мәсьәләләр уйлап чыгара башлаган. Ата-аналар аларны укыгач шаккатканнар. Шуннан бер мәсьәлә:

"Дуэйн – сутенер. Аның өч төнге күбәләге бар. Аларның хезмәте 85 доллар тора. Дуэйнның наркотик алырга 800 доллар акчасы булсын өчен күбәләкләр көнгә ничә клиент кабул итәргә тиеш?" Укытучы-"новаторны" эштән азат иткәннәр.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»ны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.


Бу очракта язылу индекслары татарча журналга – П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Алар буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып балкып керсен!



Вячеслав БИБИШЕВ



Заһир ХӘКИМОВ



Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр

Мирослав БАРТАК (Чехия)



Майк ТОШОУ (Англия)





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Гороскопны укыгач, гомеремнең икенче яртысында мине рәхәт тормыш, бәхет-шатлыклар көткәнен белдем... Эх, яшәргә иде гомернең шул икенче яртысына кадәр!

• • •

Губернаторны туктаткан полицейский хәзер асфальтта ятучы полицейский булып эшли.

• • •

Гаишник блондинканы тизлекне арттырганы өчен туктата:

— Сез шәһәр буйлап сәгатькә 90 километр белән чабасыз. Штраф түләгез!

— Нинди сәгать? Минем руль артына утырганыма да 15 минут кына бит.

• • •

Автоответчик:

— Сез хәрби комиссариатка шалтыратасыз! Әгәр дә хезмәт итәргә теләсәгез "йолдызга" басыгыз, юк икән — "рәшәткәгә".

• • •

Кытай табиблары хәсрәткә төшкән: фэн-шуй буенча яшәүчеләр һаман саен азая икән, ә менә вай-фай буенча яшәүчеләр арта гына ди.

• • •

— Әйт әле, синең хыялың бармы?

— Бар!

— Нинди?

— Татнефтькә эшкә урнашып, космоска очарга телим.

— Космоска очарга теләвеңнең кыенлыгы булмас.

• • •

Дәүләт Думасына үз-үзеңә кул салу һәм шуңа теләктәшлек күрсәтү җинаять эше булып каралачак дигән закон проекты кертелгән. Кызык, ә пенсия күләме һәм ЖКХ хезмәтенә түләү мәсьәләсе бу статьяга кертелер микән?

• • •

Безгә сум (рубль) курсының йөзеп йөриячәген аңлатканнар иде. Ә менә аның чумып-чумып алачагын әйтмәделәр, әллә оныттылар микән?..

ЧАЯН
(СКОРПИОН)
САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Рәис ИДРИСОВ

Бакчада черегән акча

Акча бездә бер букча, дигән булалар. Юк шул, акча түгел, бакчабыз гына бар.

— Шунда үсә инде ул акча, — дисезме? Үсә — көн-төн тырышсаң: сукаласаң яки казысаң, тырмаласаң, чәчсәң, утасаң, су сипсәң, уңышын үзең җыя алсаң, үстергәнеңне өстерәп ташысаң... Менә шуларны эшләп исән калсаң, бөкерәймәсәң, кәкерәймәсәң, аксамасаң, туксамасаң... Бакчаң өчен взносын түләп барсаң, насосы ватылмый суын бирсәләр, боз яумаса, кырау төшмәсә, помидор каралмаса, кыярыңны басмасалар, алмаңны урламасалар, күршеңнең умарта кортлары чагып тилмертмәсә... Хатының чирләмәсә, үзең исән-сау йөрсәң, сукыр черки тешләп аяк-кулларың шешмәсә, үлән-чәчәкләрдән аллергия булмаса... Төрле үлән кушып чәйләр эчкәч эчең китмәсә...

Файдалы, дигән булабыз бит бу эшне. Булыр файдалы?! Бил бөкерәйгәнне төзәтү өчен бүлнискә йөгерәбез — дару кирәк, анысына — акча! Акча табу өчен әйбер сату кирәк, ә бакчадагы җиләгең әле яшел, өлгермәгән. Кирәк, кирәк. Сәнәктән ясый алсак иде көрәк. Көрәк алырга да акча кирәк. Такси белән йөрсәң бакчага, акчаң кала бик сирәк. Җәяү йөрсәң ерак. Бакчаларга автобуслар бармыйлар, бездән доход килми, аларга да акча кирәк. Бу нинди хәл?! Акча – король! Акча – император! Менә килде заманнар!

Без — пенсиядә! Корольләрдән, императорлардан качып, бакчаларда ятабыз. Анда-монда кайтып телевизор карыйбыз да, хәзерге патшалар-олигархлар икәнен белеп, яңадан бакчабызга шылабыз. Аллам сакласын, ярый әле бакчабыз бар! Аны талап ала күрмәсеннәр тагын?! Хәер, кирәк булса, бездән сорап тормаслар, мөгаен. Павлов белән Гайдар дигәннәре саклык кассасындагысын шулай иткәннәр иде бит. Инде үзебез эшләгән трестны да сатып бетерделәр. Ярый әле үзебез сатуга эләкмәдек, бакчабызга качып өлгердек. Самолетлар ясый торган завод өсләреннән дә очкычлар бик күтәрелми хәзер. Аллага шөкер — күк тыныч.

Җирдә дә тыныч: заводлар шауламый, кешеләр дауламый. Президент та төпле. Халыкка өметле вәгъдәләр биреп тора.

— Камиллекнең чиге юк, — ди. Эшләргә, тырышырга кирәклеген әйтә. Үз көчеңә таянып көн күрү яхшы икәнен искәртә.

Мин дә шул фикердә. Әйтәм ич, бакчада ятабыз, дип. Үз көчебезгә ышану гына безгә юаныч бирә. Аллаһы Тәгаләдән һава шартларының әйбәтен сорап алсак, бар да булыр, иншалла... Акчасы да. Тик менә Ходаебыз акча белән эш итми шул. Белми ул акчаның нәрсә икәнен. Аңа рәхәт — акча кирәкми. Ә без аның коллары гына. Ялварасы килә:

— И, Ходаем, бетер акчаны?! Бетерсәң акчаны, олигархлар булмаячак. Калдыр безгә бары бакчаны!



ЧАЯНВОРД

Уйна да, уйла да!

АРТИСТКА ЛУАРА . . .
АРТИСТ АЙРАТ . . .
АРТИСТ . . . ХӘЙРУЛЛИН
"ЖЫЛЫ ЯКЛАРДАН . . . ИССӘЛӘР"
АРТИСТ . . . ДУРОВ
"КОШЛАР БЕЛГЕЧЕ" (-1)
ИКЕНЧЕ НОТА
ШАГЫЙРЬ . . . НӘҖМИ
ЖЫРЧЫ АЛЬБЕРТ . . .
ИТАЛЬЯН КОМЕДИЯ ПЕРСОНАЖЫ
ФРАНЦИЯДӘГЕ ШӘҺӘР
"АНДА БИК САЛКЫН . . . ЭССЕ ТҮГЕЛ" (ТУКАЙ)
"ӘйДӘ . . . ! КАЛСЫН БУ МӘШӘКАТЬ!" (ЗӨЛФӘТ)
. . . МЕДИА
"... — ГОРУР ИСЕМ" (ТАКТАШ)
"МӘҢГЕ ИДЕ ТАУЛАРЫНА"
ВАК — (-1) . . .
АЧЫ . . .
ШАЯН, ҮТКЕР
УЕНДА ТАБЫШ АЛУ
ӘЛДЕРМЕШ КАРТЫ
"ЕРАК ХӘЗЕР АРАБЫЗ, УРМАН, . . . ЛАР АЕРА"
НОТА
"АНДА БИК САЛКЫН . . . ЭССЕ ТҮГЕЛ" (ТУКАЙ)
"ӘЛЛӘ КАЯН КҮРЕНЕП . . . СОЛДАТТА БУЛГАН, ДИПӘР" (Ш. МАННАПОВ)
ХУЖА
(-1) . . . КӨЮ
. . . (-1) БОТКА КАЗАНДА
УНИВЕРСАЛЬ ТЕЛЕФОН (-2)
ӘКИЯТИ
ЧӘЧӘК
"ЖЫР ӘЙРӘТТЕ . . . ХЕР ЯШӘРГӘ" (М. ЖӘЛИЛ)
". . . БУЛСЫН" "ЮГАРЫ ОЧЫП КИЛГӘН МИНЕ КҮРГӘ ДИМЕН"
"КЫЙГАК-КЫЙГАК ИЛЕМ . . ." УРТА АЗИЯДӘ ИНЕШ
ЖИДЕ . . . НЫ БЕР БҮРЕ АШАГАН
ИШАРӘ
(-1)-ТӨЛЕК "НИНДИ ЖИТМИДЕР КҮНЕЛГӘ — ЖИЛЛӘРЕ МИКӘН?"
"РӨСТӘМ . . . ЛАРЫ" (-1) (Г. КУТУЙ)

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

1. Премия Айдан нәрсәсе белән аерыла?

2. Бөтен яктан да камил күрше кем ул?

3. Яхшы ирнең хатыны, начар иренекеннән ничек аерыла?

4. Министр трамвайда йөрсен өчен нишләргә кирәк?

5. Сайлау компаниясе вакытында барган көрәштә, гадәттә, кем җиңә?

6. Америка кешесенең рәсәйнекеннән аермасы?

ЖАВАПЛАР

1. Ай яктырта, ләкин жылытмый, премия – киресенчә. 2. Син шаулаган чакта шаулый торган кеше. 3. Яхшы ирнең хатыны эшкә күлмәген күрсәтер өчен йөри, ә начарныкы — гаиләсен туендыру өчен. 4. Бу трамвайга җемелдәп баручы сигнал приборы (мигалка) куйдырырга кирәк. 5. Кем барысыннан да күбрәк куа, шул җиңә. 6. Америкалы, авыр эш көннәреннән соң якшәмбе ял итә. Россия кешесе, авыр ял көннәреннән – дүшәмбе көн.

Сынамышларны Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 10 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **"СӘРВИНАЗ", "РӘЙХАН".**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Н. БӘДРИЕВА (Теләче р-ны, Иске Җөри ав.),
Г. ГАРИПОВА (Сарман),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Югары Арбаштан




БЕЗНЕҢ ВЕРНИСАЖ

Максим СМАГИН





Бу көннәрдә Екатеринбург үзенең данлыклы кешесе – Максим СМАГИНның 50 яшьлеген билгеләп үтә. Шәһәрдә аның күргәзмәләре, аның талантына гашыйк сәнгать сөючеләр белән очрашулар уздырыла, телевидениедән аңа багышланган тапшырулар бара, газеталарда интервьюлар чыга, мәҗлесләр гөрли... «Чаян» укучыларына Смагинның кем икәнен әйтеп торуның кирәге дә юк. Аны болай да безнең даими автор, тарих белгече, «Красная бурда» журналының рәссамы һәм шат күңелле кеше буларак беләләр. Бу вернисаж юбилярга безнең бүләгебез булсын.







4612750670080